Татарстан Республикасы

Яңа Чишмә муниципаль районының «Шахмай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Шахмай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында КАРАРЫ

2019 елның 15 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Шахмай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 октябрендәге 55-137 номерлы "Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында" карары нигезендә, 2019 елның 15 ноябрендә Яңа Чишмә муниципаль районының Шахмай авыл җирлегендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча түбәндәге мәсьәләләр каралу турында җыенның беркетмәсе төзелде: «Сез, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, көндезге формада укучы студентлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, сугыш хәрәкәтләре ветераннарының, 75тән өлкәнрәк ялгыз яшәүче гражданнардан тыш, 2020 елда үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны Шахмай авылында түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерүгә килешәсезме?:

- юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);

- юлларны кардан чистарту;

- җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, эшләр һәм килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- чишмәгә ЗСО сатып алу һәм урнаштыру (материал сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);

-Шахмай авыл зиратына хуҗалык корылмасы төзү”

«РИЗА" "КАРШЫ" "ТЫЕЛУЧЫЛАР".

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегендә барлыгы 403 граждан, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 246 граждан.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Риза» позициясе өчен 246 граждан тавыш бирде;

"Каршы" позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

"Тыелучылар» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Шахмай авылында халык җыены узган, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьлә буенча кабул ителгән карарны танырга: «2020 Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, көндезге формада укучы студентлардан, Бөек

Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, сугыш хәрәкәтләре ветераннарының, 75тән өлкәнрәк ялгыз яшәүче гражданнардан тыш, 2020 елда үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны Шахмай авылында түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерүгә килешәсезме?:

- юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- юлларны кардан чистарту;
- җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, эшләр һәм килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- чишмәгә ЗСО сатып алу һәм урнаштыру (материал сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);
- Шахмай авыл зиратына хуҗалык корылмасы төзү

3. Әлеге карарны Шахмай авыл җирлегенең мәгълүмати стенды аша халыкка җиткерергә, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

ТР Яңа Чишмә муниципаль районы
Шахмай авыл җирлеге Башлыгы — И.Г.Гаризов